МИНИСТЕРСТВО ЦИФРОВОГО РАЗВИТИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО УПРАВЛЕНИЯ, ИНФОРМАЦИОННЫХ ТЕХНОЛОГИЙ И СВЯЗИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ИДАРӘСЕН ЦИФРЛЫ НИГЕЗДӘ ҮСТЕРҮ, МӘГЪЛҮМАТ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕ ҺӘМ ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.06.2026 Казан ш. № п/179

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфа биләгәндә үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау хакында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның 8 статьясы, Татарстан Республикасы Президентының «Вазыйфа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне

дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы указлары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфа биләгәндә үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген (кушымтада бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының түбәндәге боерыкларын көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфа биләгәндә үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2021 елның 28 сентябрендәге п/255 номерлы;

«Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының 2021 елның 28 сентябрендәге п/255 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфа биләгәндә үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә үзгәреш кертү хакында» 2024 елның 18 ноябрендәге п/236 номерлы.

Министр И.С.Начвин

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының 22.06.2026 ел, № п/179 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфа биләгәндә үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «җитәкчеләр» категориясендәге вазыйфаларның иң югары төркемендәге вазыйфалары:

министрның беренче урынбасары;

Министр урынбасары, 2 штат берәмлеге.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «җитәкчеләр» категориясендәге вазыйфаларның төп төркемендәге вазыйфалары:

эшләр идарәчесе;

дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү бүлеге җитәкчесе;

тармакны планлаштыру һәм программалаштыру бүлеге җитәкчесе;

икътисад һәм социаль өлкә тармакларын цифрлы трансформацияләүне координацияләү бүлеге җитәкчесе;

мәгълүмат куркынычсызлыгын координацияләү бүлеге җитәкчесе;

элемтә хезмәтләре күрсәтүне үстерү бүлеге җитәкчесе;

бухгалтерлык хисабы һәм хисаплылык бүлеге җитәкчесе – баш бухгалтер;

кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге җитәкчесе;

хокукый тәэмин итү бүлеге җитәкчесе;

оештыру эшләре бүлеге җитәкчесе.

3. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «җитәкчеләр» категориясендәге вазыйфаларның әйдәп баручы төркемендәге вазыйфалары:

вәзгыяти үзәк эшчәнлеген тәэмин итү секторы мөдире;

икътисадый анализ һәм фаразлау секторы мөдире;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне цифрлы рәвешкә күчерү секторы мөдире;

ИТ-бергәлекне үстерү секторы мөдире.

4. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясендәге вазыйфаларның әйдәп баручы төркемендәге вазыйфалары:

министр ярдәмчесе.

5. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «белгечләр» категориясендәге вазыйфаларның әйдәп баручы төркемендәге вазыйфалары:

дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

тармакны планлаштыру һәм программалаштыру бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе, 2 штат берәмлеге;

икътисад һәм социаль өлкә тармакларын цифрлы трансформацияләүне координацияләү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе, 2 штат берәмлеге;

мәгълүмат куркынычсызлыгын координацияләү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

элемтә хезмәтләре күрсәтүне үстерү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

икътисадый анализ һәм фаразлау секторының әйдәп баручы киңәшчесе;

кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

хокукый тәэмин итү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе.

6. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «тәэмин итүче белгечләр» категориясендәге вазыйфаларның әйдәп баручы төркеме вазыйфалары:

режимлы эш һәм махсус элемтә белгече (әйдәп баручы белгеч);

бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенең әйдәп баручы белгече, 3 штат берәмлеге;

кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенең әйдәп баручы белгече;

тармакны планлаштыру һәм программалаштыру бүлегенең әйдәп баручы белгече, 2 штат берәмлеге;

оештыру эшләре бүлегенең әйдәп баручы белгече, 2 штат берәмлеге;

ИТ-бергәлек үсеше секторының әйдәп баручы белгече.